Казан шәһәре Мәскәү районы
“Ф.Аитова исемендәге татар телендә белем бирүче 12 нче гимназия” МБББУ

| “Каралды” | “Килешенде” | “Расланды” |
|---|---|---|
| Методик берләшмә җитәкчесе: | Тәрбия эшләре буенча директор | Гимназия директоры: |
| _________ / Хуҗина Р.Т. | урынбасары _______ / Рәхмәтуллина З.Н. | _________ / Нәгыймова З.Ш. |
| Беркетмә №1 | | Боерык №149 |
| “_24_” август 2020ел | “_24_” август 2020 ел | “_24_” август 2020 ел |

# “Тылсымлы каләм”
# өстәмә белем бирү берләшмәсенең
# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Төзүчесе: Газизуллина Рәмилә Гамил кызы,
өстәмә белем бирү педагогы

**2020 ел**

# Аңлатма язуы

## Программаның максатлары һәм бурычлары

- татар әдәбиятын, мәдәниятен, сәнгатен, татар журналистикасын киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру;
- яшь буында толерантлык, патриотизм хисләре тәрбияләү һәм үстерү;
- балаларның иҗади эшләренә бәя бирү һәм сәләтләрен үстерү;
- укучыларның буш вакытларын файдалы һәм нәтиҗәле оештыру;
- укучыларның эстетик зәвыкларын үстерү;
- укучыларда туган телебезгә карата ихтирам хисләрен арттыру;
- татар теленең кулланылу даирәсен киңәйтү;
- укучылар иҗатын киңәйтү, җәелдерү;
- укучыларның бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү.

## Коллектив турында кыскача белешмә

- Иҗади төркемнең составы: даими;
- укучыларны туплау үзенчәлекләре: ирекле;
- занятие төре: төркем белән;
- укыту вакыты: 1 ел;
- укучыларның саны (бер төркемдә): 15;
- укучыларның сыйныфы, яше: 4-8; 10-14 яшь;
- атналык сәгатьләр саны: 7,2;
- дәресләрне үткәрү урыны: гимназиянең Актлар залы, лекцияләр залы, китапханә, медиотека, Туфан Миңнуллин истәлегенә багышланган Мемориаль зал, Татарстан Республикасы Милли мәгариф музее, Фатиха Аитова музее.

## Программаны үтәүдә катнашучылар турында кыскача белешмә

1. Газизуллина Рәмилә Гамил кызы - Журналистика һәм татар теле һәм әдәбияты буенча югары белеме булган педагог, Татарстан Республикасы һәм Халыкара Журналистлар Берлекләре әгъзасы, “Бәллүр каләм” республика бүләге иясе (программаның “теория” һәм “практика” өлешләрен үтәү өчен), “Истә калганнар” (2016 ел) китабы авторы;
2. Татарстан Республикасының танылган мәдәният һәм сәнгать әһелләре, журналистлар, галимнәр, табиблар һ.б.

Укытучы алдына куелган бурыч – иҗади берләшмә утырышларын мөмкин кадәр мавыктыргыч, җанлы, кызыклы итеп, төрле традицион һәм заманча алымнар кулланып үткәрүдән гыйбарәт.

Халык авыз иҗаты материалларыннан: әкият, табышмак, мәкаль-әйтемнәрдән файдалану бер үк вакытта ике бурычны үтәүгә хезмәт итә: беренчедән, алар укучыларга татар әдәбиятыннан, фольклорыннан белешмә бирә; икенчедән, иҗади эштә файдалану өчен материал булып тора.

Түгәрәк алдында торган иң мөһим бурычларның берсе шул: иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан, укучылар “Ялкын”, “Сабантуй”, “Сөембикә”, “Салават күпере”, “Сәхнә”, “Идел” журналларын, “Көмеш кыңгырау”, “Татарстан яшьләре”, “Ватаным Татарстан” газеталарын даими укып барырга, татар спектакльләрен, балалар өчен татарча телевидение һәм радио тапшыруларын карарга һәм тыңларга, яңа чыккан әдәби әсәрләр белән танышып барырга тиешләр.

Уку елы башында балалар өчен булган вакытлы матбугатка күзәтү оештырыла. Укучыларның игътибарын газета-журналлардагы рубрика төрләренә, шигырьләрнең, мәкаләләрнең тематикасына, күтәрелгән проблемаларның актуальлегенә юнәлтү сорала.

Укучылар белән эшләү барышында аларның шәхси үзенчәлекләрен истә тоту бик әһәмиятле. Мәсәлән, һәр укучыга да шигырь язу сәләте бирелмәскә мөмкин. Кемдер үзен әкият иҗат итүдә, мәкалә язуда сынап карый ала. Кемдер вакытлы матбугатта басылган материалларны туплап, эшкәртеп, мәктәп газетасы өчен әзерләргә мөмкин. Шунлыктан, иҗади берләшмә җитәкчесе алдында укучыларның иҗади сәләтләрен ачу һәм үстерү буенча җитди бурыч тора.

Укучылар эпитет, гипербола, литота, метафора, метанимия, сынландыру кебек сурәтләү чаралары турында хәбәрдәр булырга, аларны таный белергә, үз иҗатларында куллана белергә тиешләр. Бу сурәтләү чаралары белән таныштырганда үз шәһәрләрендә иҗат итүче күренекле язучы һәм шагыйрьләрнең әсәрләреннән файдалану аеруча отышлы. Милли-төбәк компонентларыннан урынлы файдалану балаларда якташлары белән горурлану хисләре уята, патриотик тәрбия бирә.

Укучыларны Журналистиканың хәбәри (информацион) жанрлары белән таныштыру сорала:

- хәбәр
- хисап
- репортаж
- интервью

Вакытлы матбугаттан һәр төргә дә күзәтү ясалырга, хәбәри жанрда иҗат итү, язу үзенчәлекләре билгеләнергә тиеш. Практик дәресләрдә укучылар хәбәри жанрда иҗат итәләр. Уңышлы эшләр гимназиянең “Кызлар иле” газетасында урын ала.

Ел ахырында түгәрәккә йөрүче укучы түбәндәгеләрне белергә тиеш:

- телдән һәм язмача бәйләнешле сөйләм төзергә;
- актуаль темага хәбәр, репортаж, интервью язарга;
- якташ язучы һәм шагыйрьләрнең иҗатларын белергә;
- шигъри рифмалар уйлап табарга;
- ел дәвамында әдәбият һәм сәнгать әһелләренә кагылышлы истәлекле даталар турында хәбәрдар булырга;
- язылган материалны редакцияләргә, компьютерда бастырырга;
- радио өчен сценарий, радиотекст төзи-яза белергә.

## Программаны чынга ашыру чаралары

| № | Тема /Чаралар | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1. | Инструктаж. Журналистикага кереш/ Танышу дәресе | 2 сәг. |
| 2. | Практика. Текст белән эш/ Телшомарткычлар. | 2 сәг. |
| 3. | “Фатиха.FM” радиосы. Укучыларны радио тарихы, эшчәнлеге белән таныштыру. | 2 сәг. |
| 4. | Радиотекст. Сценарий төзү нечкәлекләре. | 2 сәг. |
| 5. | Журналист этикасы. | 2 сәг. |
| 6. | Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре/ Тизәйткечләр. | 2 сәг. |
| 7. | “Редакциядә эшне оештыру алымнары”. Эш кәгазьләре. Уен-дәрес. | 2 сәг. |
| 8. | Журналист һәм мәгълүмат чаралары. Брейн-ринг темасы: “Казан шәһәрендә чыгып килүче татар телендәге газета-журналлар”. | 2 сәг. |
| 9. | Өлкәннәр һәм укытучылар көненә радиотапшыру әзерләү. | 2 сәг. |
| 10. | “Яңалыклар үзәгендә – журналист”. Хәбәр язу. | 2 сәг. |
| 11. | Балалар журналлары. “Тылсымлы куллар”, “Сабантуй” журналлары белән танышу. | 2 сәг. |
| 12. | Газетада баш исемнәр. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 13. | Гимназиядә музей көне. Чарадан репортаж язу. | 2 сәг. |
| 14. | Практика. Гимназиянең “Кызлар иле” газетасы. | 2 сәг. |
| 15. | Газета-журналлар эшчәнлеге белән таныштыру. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре. | 2 сәг. |
| 16. | “Кызлар иле” газетасына мәкаләләр, хәбәрләр әзерләү. | 2 сәг. |
| 17. | Журналистикада - сәяхәтнамә. | 2 сәг. |
| 18. | Экскурсия. “Кызлар иле” газетасында “евроремонт”. Үсеш баскычлары. Яңа рубрикалар булдыру. | 2 сәг. |
| 19. | Газеталарның төрләре: иҗтимагый-сәяси, мәдәни, әдәби һ.б. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 20. | “Татмедиа”да кунакта. Редакцияләргә экскурсия. | 2 сәг. |
| 21. | Радио көне. Әниләр көненә радиотапшыру әзерләү. | 2 сәг. |
| 22. | Практик дәрес. “Татмедиа”га булган экскурсия турында язу. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 23. | Журналистның хокук-бурычлары. Уен-дәрес. | 2 сәг. |
| 24. | “Зирәк хәбәрче” интеллектуаль уены. | 2 сәг. |
| 25. | Инвалидлар декадасына багышланган чараларны яктырту. Репортаж. | 2 сәг. |
| 26. | Инвалидлар декадасына багышланган “Рухи ярдәм” акциясен оештыру. | 2 сәг. |
| 27. | Татарстан Республикасы Журналистлар Берлегенә сәяхәт. Күренекле журналистлар белән очрашу. | 2 сәг. |

| | | |
|---|---|---|
| 28. | Практика. Чарадан репортаж. | 2 сәг. |
| 29. | Г.Камал, К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт театрларына сәяхәт. | 2 сәг. |
| 30. | “Татар театрына – 113 ел” темасына әңгәмә. | 2 сәг. |
| 31. | Тележурналистиканың актуаль мәсьәләләре. | 2 сәг. |
| 32. | Радиотекст. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 33. | Гимназиядә – Яңа ел. Фоторепортаж. | 2 сәг. |
| 34. | Химиклар сараена сәяхәт. Фоторепортаж. | 2 сәг. |
| 35. | “Кызлар иле” газетасын әзерләү. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 36. | Материаллар җыю, редакцияләү буенча күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 37. | Газета версткасы һәм дизайны буенча күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 38. | Практика. | 2 сәг. |
| 39. | Радиотекст. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 40. | Редакциянең вазыйфасы. Корректорның әһәмияте. | 2 сәг. |
| 41. | Клавиатура төзелеше, хәрефләр, символлар урнашуы белән таныштыру. | 2 сәг. |
| 42. | Хәреф җыю режимнары (тел, баш хәреф). Татар хәрефләре | 2 сәг. |
| 43. | Абзац. Абзацны форматлау. | 2 сәг. |
| 44. | Радиода күнекмәләр. “Муса Җәлил тууына – 110 ел!” темасына мәгълүмат туплау. | 2 сәг. |
| 45. | М.Җәлилне искә алу көне, әсәрләре белән танышып, аңа ияреп шигырь язу. | 2 сәг. |
| 46. | Текст фрагментлары белән эшләү (күчерү, өстәп кую, нөсхәләү). | 2 сәг. |
| 47. | Татарстан Язучылар Берлегенә сәяхәт. Тукай клубы эшчәнлеге белән танышу. | 2 сәг. |
| 48. | Чарадан репортаж. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 49. | Текст эченә өстәлмәләр урнаштыру. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 50. | "Ялкын" журналының рубрикаларын күзәтү. Ошаган рубрикага хәбәр язу. | 2 сәг. |
| 51. | Журналистиканың хәбәри (информацион) жанры төркеме: хәбәр. ММЧтан мисаллар барлау. | 2 сәг. |
| 52. | Практика. Уен-дәрес. | 2 сәг. |
| 53. | Журналистиканың хәбәри (информацион) жанры төркеме: хисап. ММЧтан мисаллар барлау. | 2 сәг. |
| 54. | Практика. Дәрес-экскурсия. | 2 сәг. |
| 55. | Журналистиканың хәбәри (информацион) жанры төркеме: репортаж. ММЧтан мисаллар барлау. | 2 сәг. |
| 56. | Практика. Музей эшчәнлеге белән танышу. | 2 сәг. |
| 57. | Журналистиканың хәбәри (информацион) жанры төркеме: интервью. ММЧтан мисаллар барлау. | 2 сәг. |
| 58. | Редакторның вазыйфасы һәм бурычлары. | 2 сәг. |
| 59. | Хаталы текстны редакцияләү күнекмәләре. | 2 сәг. |

| | | |
|---|---|---|
| 60. | Хаталарның төрләре. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 61. | Радио. “Апрель – Тукай ае” темасына материал туплау һәм радиодан чыгышка әзерләнү. | 2 сәг. |
| 62. | Радиодан “Апрель – Тукай ае” темасына чыгыш ясау. Практик дәрес. | 2 сәг. |
| 63. | Әдәби әсәрләрдә сурәтләү чаралары. Эпитет. Сынландыру. Метонимия. Күнекмәләр. | 2 сәг. |
| 64. | Радио. “Җиңү көне” темасына шигырьләр өйрәнү һәм гимназия радиосыннан чыгыш ясау. | 2 сәг. |
| 65. | Практика. “Без – Тукай оныклары” тапшыруына әзерләнү. | 2 сәг. |
| 66. | “Без – Тукай оныклары” тапшыруының иҗат төркеме белән очрашу. Камерага чыгыш ясау. | 2 сәг. |
| 67. | Казан паркларына экскурсия. Чарадан – фоторепортаж. | 2 сәг. |
| 68. | Ел буена тупланган материалларны “Кызлар иле” газетасында бастыру. Практик эш. | 2 сәг. |
| 69. | “Ел хәбәрчесе” бәйгесе | 2 сәг. |
| 70. | Гимназиянең “Кояшкай” җәйге лагерена әзерлек. | 2 сәг. |
| | **Барлыгы: 140 сәгать** | |

- **2 төркем дә әлеге план буенча белем өсти.**
- **Дәресләр вакыты 1 төркемгә нигезләнеп төзелде.**